БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«02» 07 2026 ел

**КАРАР**
№ 209

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясы, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм савыктыру оешмаларына санитария-эпидемиология таләпләре»нең СанПиН 2.4 3648-20 санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүнең кушымтада бирелгән Тәртибен (алга таба — Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район Башкарма комитетының «Балтач районы гомуми белем бирү оешмаларына 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны беренче сыйныфка кабул итү Тәртибен раслау турында» 2014 елның 27 июнендәге 265 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «02» 07
209 номерлы карары белән
расланды

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Тәртибе

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүнең әлеге Тәртибе (алга таба - Тәртип), шулай ук Мәгариф идарәсенең һәм аның карамагындагы белем бирү оешмаларының үзара хезмәттәшлеге тәртибе Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүгә рөхсәт бирү буенча учредитель функцияләрен башкаручы «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан тәртипкә салына.

1.2. Әлеге Тәртип түбәндәге норматив документларга туры китереп эшләнде:

- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон;
- Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «СП 2.4 3648-20 номерлы «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм савыктыру оешмаларына санитария-эпидемиология таләпләре» санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары;
- Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы (алга таба - кабул итү Тәртибе).

1.3. Белем бирү оешмасының беренче сыйныфына 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү учредитель функцияләрен башкаручы «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ рөхсәте буенча гамәлгә ашырылырга мөмкин.

### 2. Эшне оештыру

(законлы вәкилләргә) «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ га турыдан-туры яки сайланган гомуми белем бирү учреждениесе аша мөрәҗәгать итүе кирәк.

Ата-ана (законлы вәкил) гомуми белем бирү учреждениесенә мөрәҗәгать иткән очракта, алар тарафыннан «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ га түбәндәге документлар тәкъдим ителә:

- ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасының билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе (1-нче кушымта);

- баланың туу турында таныклыгының билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе;

- сәламәтлек торышы буенча каршылыклар булмавын раслый торган документ күчермәсе.

2.2. Документларны кабул итү турында карар кабул ителгәннән соң, комиссия секретаре гаризаны 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү буенча гаризаларны теркәү һәм рөхсәт бирү журналына терки (5 нче кушымта).

2.3. Баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) гаризадагы имзасы нигезендә аларның үзләренең шәхси мәгълүматларын һәм баланың шәхси мәгълүматларын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эшкәртүгә ризалыгы раслана (2 нче кушымта).

2.4. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризалары «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы боерыгы белән төзелгән комиссия утырышында карала. Комиссия үз эшен 1 апрельдән 5 сентябрьгә кадәрге чорда башкара. Комиссия эшенең сроклары ел саен «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ боерыгы белән билгеләнә. Гариза бирүчеләргә комиссия эшенең урыны һәм вакыты турында бер атна алдан хәбәр ителә.

2.5. Комиссия эшенең предметы - баланың яшь нормасына туры килә торган гомуми үсеш дәрәҗәсен һәм гомуми белем бирү учреждениесендә укуга психологик әзерлеген ачыклау.

2.6. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ комиссиясенең бәяләмәсе нигезендә мөрәҗәгать итүчегә (ата - анага яки законлы вәкилгә) 6 яшь ярымнан кечерәк булган балаларны беренче сыйныфка укырга кабул итүгә рөхсәт яки мондый рөхсәттән баш тарту турында хәбәр итә; 8 яшьтән өлкәнрәк булган очракта- мөрәҗәгать итүчегә (ата-анага яки законлы вәкилгә) балаларны беренче сыйныфка укырга кабул итүгә рөхсәт бирелә (3 нче һәм 4 нче кушымта).

2.7. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга иртәрәк яки соңрак яшьтә балаларны кабул итүгә рөхсәт яки аны бирүдән баш тарту турында комиссия карарыннан соң биш көн эчендә дәлилләнгән хәбәрнамә җибәрелә.

2.8. Иртәрәк яшьтә башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча балаларны укырга кабул итүгә рөхсәт бирүдән түбәндәге очракларда баш тартылырга мөмкин:

- әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы пакеты булмау;

- тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документлар бирү;

- мәктәпкәчә яшьтәге баланың ата-аналарының (законлы вәкилләренең) башлангыч мәктәп яшендәге балалар өчен белем бирү процессын оештыру шартлары белән килешмәве;

- сәламәтлек торышы буенча медицина каршылыклары булу.

2.9. Башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча балаларны иртәрәк яисә соңрак яшьтә укырга кабул итүгә рөхсәт алганнан соң, гомуми белем бирү учреждениесе югарыда күрсәтелгән балаларны тиешле гомуми белем бирү учреждениесенә кабул итү кагыйдәләре нигезендә беренче сыйныфка кабул итә.

2.10. Балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча соңрак яшьтә укырга кабул итүгә рөхсәт бирелгән очракта, «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ бу хакта Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә хәбәр итәргә тиеш.

2.11. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризалары, балаларны кабул итүгә рөхсәт, шулай ук кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә махсус журналда теркәлә.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Тәртибенә 1 нче кушымта

Теркәлү номеры ________

«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына

______________________________________

Ата-ана (законлы вәкил), кирәкмәгәнне сызып ташларга
ФИО

______________________________________

______________________________________

Теркәлү (яшәү)урыны

______________________________________

______________________________ урамы
йорт_____ корп_________
Телефон: _____________
кәрәзле тел.:_________________________

Электрон почта адресы________________

6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүгә рөхсәт бирү турында

Гариза

______________________________________________________________

(мәгариф учреждениесе исеме)

баламны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга беренче сыйныфка кабул итүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм

______________________________________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Баланың туган көне, ае, елы_____________________________________

Гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен белем бирү процессы шартларына һәм оештыруга карата гигиена таләпләрен тулы булмаган күләмдә үтәве турындагы мәгълүмат белән таныштырылды.

Белем бирү процессының булган шартлары белән килешәм/ килешмим

Гомуми белем бирү учреждениесе уставы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны регламентлый торган башка документлар белән таныштырылды.
«______ »____________________20_____ел

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән тәртиптә шәхси мәгълүматларны һәм баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә риза______

Гаризага түбәндәге документларны терким (кирәклесен V белән билгеләргә);

баланың туу турында таныклыгы күчермәсе;

баланың законлы вәкиле (уллыкка алучысы, опекуны) вәкаләтләрен раслый торган документның күчермәсе;

мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслый торган документның күчермәсе - чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар өчен;

баланың сәламәтлеге торышы турында медицина белешмәсе, аның сәламәтлеге торышы буенча уку өчен комачаулый торган күрсәтмәләре булмавын раслый;

гаризаны карау нәтиҗәләре турында миңа почта, электрон почта, телефон аша хәбәр итүегезне сорыйм (кирәклесен ассызыклау).

Дата___________________ ______________________________________

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Тәртибенә 2 нче кушымта

Баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык

______________________________________________

______________________________________________

паспорт мәгълүматлары: ______________________________ ,
(номеры, сериясе (кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________________ның
фамилиясе, исеме, атасының исеме, баланың туу датасы

анасы / атасы буларак (кирәклесен ассызыкларга)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә баламның шәхси мәгълүматларын «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ муниципаль казна учреждениесенә автоматлаштыру чараларын кулланып яки андый чараларны кулланмыйча, шул исәптән әлеге мәгълүматларны архивларда саклауны һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә урнаштыруны да кертеп, эшкәртүгә ризалык бирәм.

Мин эшкәртүгә ризалык биргән шәхси мәгълүматлар исемлеге:

- баланың ФИА;
- баланың туган көне;
- адресы;
- туу турында таныклык мәгълүматлары;
- сәламәтлек торышы турында белешмәләр.

Шәхси мәгълүматларга керү мөмкинлеге баланың ата-анасына (законлы вәкиленә), шулай ук «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ муниципаль казна учреждениесе һәм гомуми белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренә дә бирелергә мөмкин.

Мин «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ муниципаль казна учреждениесенә шәхси мәгълүматлар белән түбәндәге гамәлләрне (операцияләрне) башкарырга хокук бирәм:

- җыю;
- файдалану;
- системалаштыру;
- шәхессезләндерү;
- туплау;
- бикләү;
- саклау;
- юк итү;
- төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү).

Мин «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ муниципаль казна учреждениесе минем баламның әшкәртелә торган шәхси мәгълүматларын исемлекләргә (реестрларга) һәм мәгариф белән идарә итүнең федераль һәм муниципаль органнарының хисап мәгълүматларын бирүне регламентлаштыручы норматив документларында каралган хисап формаларына кертергә хокуклы булуы белән килешәм.

Әлеге ризалык минем тарафтан бирелде һәм ___________________________ кадәр гамәлдә.
дата

Мин, «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ муниципаль казна учреждениесе адресына почта аша заказлы хат белән җибәрелергә яки «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ муниципаль казна учреждениесенә расписка белән тапшырылырга мөмкин булган тиешле язма документ төзү юлы белән ризалыгымны кире алу хокукын үземдә калдырам.

Имза_______________________________

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Тәртибенә 3 нче кушымта

Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк баланы укырга алуга рөхсәт

«________» ________________________20___ел

______________________________________________________________________

«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, гражданның (гражданка) аның малаен/кызын (кирәклесен ассызыкларга)____________________________
_________________________________________________________________(ФИА)
«_____» ______________20___елда туган, укырга алуны сорап язган гаризасын һәм беркетелгән документларын (яки муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе администрациясенең үтенечнамәсен) карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм савыктыру оешмаларына санитария-эпидемиология таләпләре»нең СП 2.4 3648-20 санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы нигезендә агымдагы елның 1 сентябренә алты яшь ярым булмаган баланы укырга алырга рөхсәт бирә.

«Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.К.Мөхәрләмов

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Тәртибенә 4 нче кушымта

6 яшь ярымнан кечерәк яисә сигез яшьтән өлкәнрәк булган баланы башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында ХӘБӘРНАМӘ

«_______ »_____________________ 20___ел

_______________________________________________

«ТР БРИК мәгариф идарәсе» МКУ, гражданның (гражданка) аның малаен/кызын (кирәклесен ассызыкларга) ______________________________________ (ФИА)

«_____»______________20___елда туган, укырга алуны сорап язган гаризасын һәм беркетелгән документларын (яки муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе администрациясенең үтенечнамәсен) карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы (2013 елның 2 июлендәге үзгәрешләр белән) Федераль законнар, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, ял итү һәм савыктыру оешмаларына санитария-эпидемиология таләпләре»нең СанПиН 2.4 3648-20 санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы нигезендә ________________________________________ ФИА,

________________________________
баланың туган көне

башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга алырга рөхсәт бирүдән түбәндәге сәбәп нигезендә ______________________________
сәбәбе күрсәтелә

баш тарту турында хәбәр итә.

«Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.К.Мөхәрләмов

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү Тәртибенә 5 нче кушымта

Агымдагы елның 1 сентябренә 6 яшь ярымнан кечерәк һәм 8 яшьтән өлкәнрәк булган 1 сыйныфка баручы балаларның гаризаларын теркәү журналы

«______»_____________ 20__ ел башланды
«______»_____________ 20__ ел тәмамланды

____________________ 20___ ел

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы, агымдагы елның 1 сентябренә яше | Белем бирү оешмасының исеме | Гариза бирү датасы | Ата – ананың ФИА, контактлы телефон номеры / йорт адресы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |